**Татарстан Республикасы**
**Дәүләт Советы Президиумы**

# КАРАРЫ

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын үзгәртү һәм штат санын кыскарту турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын төзү турында” 2014 елның 1 октябрендәге 11-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрнең исемнәрен үзгәртергә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеген Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеген Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә.

2. “Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын үзгәртү һәм штат санын кыскарту турында” 2010 елның 22 октябрендәге 1205-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге” позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге”;

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге” позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге”.

3. “Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын үзгәртү һәм штат санын кыскарту турында” 2010 елның 22 октябрендәге 1205-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына 2 нче кушымтаны кушымтада бирелгән редакциядә бәян итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, әлеге карар белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына кертелгән үзгәрешләргә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының штат расписаниесенә үзгәрешләрне әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе раславына кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2014 елның 23 октябре
№ 42-V ДС